КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 сентябрь г.Казань № 848

Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкару өчен муниципаль район составына керә торган җирлекләр бюджетларына субвенцияләр хисаплап чыгару һәм бирү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында» 2011 ел, 27 гыйнвар, 48 нче карары үз көчен югалткан дип тану турында

«Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны башкаруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр

исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына бирү турында» 2006 елның 16 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын (алга таба – вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисап) расларга.

2. Бу карар белән расланган форма буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турындагы хисап Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 7 сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, хисаплылыкны үзәкләштереп җыю буенча «Барс.Web-Своды» мәгълүмат-аналитика системасыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә бирелә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкару өчен муниципаль район составына керә торган җирлекләр бюджетларына субвенцияләр хисаплап чыгару һәм бирү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында» 2011 ел, 27 гыйнвар, 48 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 9 сентябрь, 848 нче
карары белән расланды

Форма

_____ елның __________ кварталына территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында

# хисап

<table>
<tr><td rowspan="4">Муниципаль берәмлек исеме</td><td colspan="3" rowspan="2">Хәрби исәпкә алу хезмәткәрләре саны</td><td colspan="3" rowspan="2">Эш вакыты коэффициентын исәпкә алып, хәрби исәпкә алу хезмәткәрләре саны</td><td colspan="9">Җирле үзидарә органының бер хәрби исәпкә алу хезмәткәрен тоту чыгымнары</td><td colspan="3">Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен исәпләнгән субвенция күләме</td><td colspan="3">Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган субвенция күләме</td></tr>
<tr><td rowspan="3">барлыгы</td><td colspan="8">шул исәптән:</td><td rowspan="3">барлыгы</td><td colspan="2">шул исәптән:</td><td rowspan="3">барлыгы</td><td colspan="2">шул исәптән:</td></tr>
<tr><td rowspan="2">барлыгы</td><td colspan="2">шул исәптән:</td><td rowspan="2">барлыгы</td><td colspan="2">шул исәптән:</td><td rowspan="2">хезмәт өчен түләү һәм хезмәт өчен түләүгә исәпләүләр буенча</td><td rowspan="2">беренчел хәрби исәпкә алуны матди-техник яктан тәэмин итүгә</td><td colspan="6">шулардан:</td><td rowspan="2">хезмәт өчен түләү һәм хезмәт өчен түләүгә исәпләүләр буенча</td><td rowspan="2">беренчел хәрби исәпкә алуны матди-техник яктан тәэмин итүгә</td><td rowspan="2">хезмәт өчен түләү һәм хезмәт өчен түләүгә исәпләүләр буенча</td><td rowspan="2">беренчел хәрби исәпкә алуны матди-техник яктан тәэмин итүгә</td></tr>
<tr><td>азат ителгән</td><td>берьюлы ике эш башкару буенча</td><td>азат ителгән</td><td>берьюлы ике эш башкару буенча</td><td>урыннарны арендага алу өчен түләү буенча</td><td>элемтә хезмәте күрсәтүләр өчен түләү буенча</td><td>транспорт хезмәте күрсәтүләр өчен түләү буенча</td><td>командировка хезмәте күрсәтүләр өчен түләү буенча</td><td>коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча</td><td>җиһаз, инвентарь, оештыру техникасы, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү чыгымнары өчен түләү буенча</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2=3+4</td><td>3</td><td>4</td><td>5=6+7</td><td>6</td><td>7</td><td>8=9+10</td><td>9</td><td>10=11+12+13+14+15+16</td><td>11</td><td>12</td><td>13</td><td>14</td><td>15</td><td>16</td><td>17=18+21</td><td>18=9*5</td><td>19=10*5</td><td>20=21+22</td><td>21</td><td>22</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

Җитәкче _____________ ______________________
(имзасы) (имзаны таркатып язу)

Баш бухгалтер _____________ ______________________
(имзасы) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы _____________ ___________ ______________________ __________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу) (телефоны)

______ ел, «____» ________________

М.У.

___________________________________________________________________